| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2017 Казан ш. № 10-12/кс

«Казан медицина аппаратурасы заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлаганга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карарга кушымта нигезендә су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казан медицина аппаратурасы заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлаганга календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.
2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казан медицина аппаратурасы заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
26.05.2017 ел № 10-12/кс карарына
кушымта

## Су бүлүне гамәлгә ашыручы «Казан медицина аппаратурасы заводы» ачык акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлаганга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Агынты суларны транспортлаганга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | Карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Казан медицина аппаратурасы заводы» ачык акционерлык җәмгыяте* | 7,19 | 7,19 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге